СОВЕТ ТАВЕЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Нагорная, д.70, с. Тавели,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422160

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАУИЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Таү өсте урамы, 70 йорт, Тауиле авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы, 422160

Тел. (факс): (85563) 2-67-25 e-mail: Tavel.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

**Решение** **Карар**

20 февраль 2023 ел. № 5-21

Тауиле авыл җирлеге Советының 2016 елның 3 мартындагы № 1-6 карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге № 273 ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 05 декабрендәге № 498-ФЗ номерлы федераль законнар, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Тауиле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Тауиле авыл җирлеге Советының 2016 елның 3 мартындагы № 1-6 карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 1 нче кушымтаның 7.1 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 11 пунктын өстәргә:

"11) аларга чит ил агенты статусын алу.";

1.2. Нигезләмәнең 7 бүлегендәге 7.1 пунктының 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) Россия Федерациясе гражданлыгын йә чит ил гражданлыгын (подданлыгын) туктату - Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы, аның нигезендә чит ил гражданы муниципаль хезмәттә булырга хокуклы.»;

1.3. Нигезләмәнең 12 бүлегендәге 12.3 пунктының 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) индивидуаль (персональләштерелгән) исәп системасында теркәлүне раслаучы документ, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш»;

1.4. Нигезләмәнең 12 бүлегендәге 12.19 пунктының 2 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга.
1.5. «Россия Федерациясе Пенсия фонды» Нигезләмәсенең 24 бүлегендәге 24.2 пунктының 4 пунктчасында «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды» сүзләре белән алмаштырырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлеге Советының мәгълүмат стендларында, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Интернет-телекоммуникация челтәрендә Мамадыш муниципаль районы http://mamadysh.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районының Тауиле авыл җирлеге башлыгы В.И.Ивановка йөкләргә.

Җирлек башлыгы,
Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Тауиле авыл җирлеге
Советы рәисе
В.И.Иванов